ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.7, пос. Октябрьский,
422580

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 7 нче йорт, Октябржский авылы,
422580

Тел.: (84379) 31-4-27, факс: (84379) 31-4-27.

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең Октябрьский поселогы Школьная урамындагы 10 нчы күпфатирлы торак йортта яшәүче гражданнарның җыены нәтиҗәләре турында

№4 04.12.2021

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 27 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре буенча түбәндәге мәсьәлә буенча беркетмә төзелде:
"Сез 2022 нче елда Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Октябрьский поселогы Школьная урамындагы 10 нчы күпфатирлы торак йортта яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- йорт яны балалар мәйданчыгы өчен инвентарь сатып алу

Халык җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 13 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 13 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 13 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Октябрьский поселогы Школьная урамындагы 10 нчы күпфатирлы торак йортта яшәүчеләрнең халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танылды.

2. 2022 нче елда Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Октябрьский поселогы Школьная урамындагы 10 нчы күпфатирлы торак йортта яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле

әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза буласызмы? :

йорт яны балалар мәйданчыгы өчен инвентарь сатып алу, дигән сорау буенча карарны таныргa.

3. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Октябрьский поселогы Школьная урамындагы 10 нчы күпфатирлы торак йортта яшәүче гражданнарының җыены нәтиҗәләрен Октябрьский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен әлеге карарны җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: А.С. Назаров